ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«18» 11 2025 г.

**КАРАР**

№ 272

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Башлыгының 2012 елның 12 декабрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында Нигезләмәне раслау хакында» 175 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Закон таләпләренә туры килүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач муниципаль район Башлыгы карар бирә:

1. Карар преамбуласында «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 январендагы 5-ТРЗ номерлы» сүзтезмәсен «2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы» сүзтезмәсе белән алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Башлыгының 2012 елның 12 декабрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. 2.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупциячел хокук бозуның факттагы шартлары бәян ителгән докладыннан һәм муниципаль хезмәткәрнең ризалыгы белән һәм коррупциячел хокук бозу фактын таныган очракта гына язмача аңлатмасыннан (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге җәза кулланудан тыш)).»;

2.2. 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дисциплинар җәзалар куллану һәм бетерү тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш.»;

2.3. 2.5 пунктның 2 абзацында «яисә «коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4

статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан» сүзләрен өстәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль район Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Балтач муниципаль
район Башлыгы Р.Р.Нотфуллин